Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы җирлеге Нолинка авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

3 август 2026 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2026 елның 3 августында 18 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл авыл җирлеге бюджетына 2026 елда 1 375 000 сум 00 тиен күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 29 ноябрендәге 9 номерлы, "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында 2026 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 10 номерлы карарларына нигезләнеп, «урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру (урам яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру); торак пункт территориясен төзекләндерүгә билгеләнгән әлеге акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлауга (вак таш сатып алу, юлларны асфальтлау, асфальт юллардагы чокырны ремонтлау, юлларга вак таш җәю)» юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 141 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 80 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 80 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл авыл җирлеге бюджетына 2026 елда 1 375 000 сум 00 тиен күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2025 елның 29 ноябрендәге 9 номерлы, "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында 2026 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 10 номерлы карарларына нигезләнеп, «урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элементләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру (урам яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру); торак пункт территориясен төзекләндерүгә билгеләнгән әлеге

акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлауга (вак таш сатып алу, юлларны асфальтлау, асфальт юллардагы чокырны ремонтлау, юлларга вак таш җәю)» юнәлдерү белән килешәсезме? турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Нолинка авылы, Лесная урамы, 3 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С.Ларин